

**Хөрмәтле Альта Хаҗиевна!**
Сибелеп яткан татар тарихын бер тәсбих итеп җыйнау, андагы ак тапларны бетерү  юнәлешендә Сез башкарган хезмәтләр гаять зур фәнни кыйммәткә ия. Татар халкының  мәгърифәтче хатын-кызларына багышланган  тирән эчтәлекле фәнни эшләрегез, авылларыбыз, гомумән, төбәгебез тарихын торгызуга куйган көчегез, һичшиксез, киләчәк буыннар тарафыннан да кат-кат бәяләнәчәк әле.
Сезне олуг гомер бәйрәмегез - 80 яшьлек юбилеегыз белән чын күңелдән  тәбрик итәм. Киләчәктә дә шундый күңел көрлеге, ташып торган хезмәт дәрте белән гомер итәргә, яңадан-яңа хезмәтләр язарга насыйп булсын!
Сезгә корычтай нык сәламәтлек, озын гомер, җан тынычлыгы, рух ныклыгы, зиһен байлыгы һәм иҗат уңышлары телим!
Ихтирам белән, Илдар НӘФЫЙКОВ.